КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль г.Казань № 180

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 март, 179 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 846 нчы; 2020 ел, 28 февраль, 153 нче; 2020 ел, 25 август, 734 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1172 нче; 2021 ел, 26 июль, 649 нчы, 2021 ел, 7 декабрь, 1182 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 3.3.18[1] пунктча өстәргә:

«3.3.18[1]. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи;»;

3.3.37 пунктчага «шул исәптән XML-документлар форматындагы белешмәләрнең күчемсез мөлкәт бердәм дәүләт реестрына кертелүгә юнәлдерелгән

гамәлләрне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары нигезендә мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрен, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зоналары чикләрен, аларга үзгәрешләр кертү, аларның гамәлдә булуын туктату чикләрен раслау турында, әлеге документларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән әлеге документларның электрон рәвешләрен раслый.» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин